**ГЛАВА**
**БОЛЬШЕКАБАНСКОГО**
**СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**
**ЛАИШЕВСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул.Южная, дом 1, село. Малые Кабаны
422623, телефон/факс(84378)4-22-02
E-mail: Bkab.La@tatar.ru

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ**
**РАЙОНЫ**
**ОЛЫ КАБАН ҖИРЛЕГЕ**
**БАШЛЫГЫ**
Кәньяк урамы, 1 нчы йорт,
Кече Кабан авылы,
422623 телефон/факс(84378)4-22-02
E-mail: Bkab.La@tatar.ru

---

**2025елның «20» гыйнвары** **1номер**

## КАРАР

**Җир кишәрлегеннән файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү мәсьәләсе буенча гавами тыңлаулар билгеләү турында**

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 39 статьясы, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының «Олы Кабан авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 20 статьясы нигезендә, территориянең тотрыклы үсешен, инженерлык транспорт һәм социаль инфраструктураларны үстерүне тәэмин итү, гражданнар һәм аларның берләшмәләре мәнфәгатьләрен исәпкә алуны тәэмин итү максатларында Олы Кабан авыл җирлеге башкарма комитеты Шәфигуллин Айрат Илдус улы гаризасы нигезендә КАРАР БИРӘ:

1.ТР, Лаеш муниципаль районы, Кече Кабан авылында урнашкан, 16:24:160202:460 кадастр номерлы, 693 кв.м мәйданлы җир кишәрлегеннән файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә «ИЖС» тан «кибетләргә» рөхсәт бирү мәсьәләсе буенча гавами тыңлаулар билгеләргә.

2. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Олы Кабан авыл җирлегендә җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проектын әзерләү комиссиясе 2025 елның 12 февралендә 15.00 сәгатьтә Олы Кабан авыл җирлеге башкарма комитеты бинасында гавами тыңлаулар үткәрергә тиеш. Адресы: ТР, Лаеш муниципаль районы, Кече Кабан авылы, Көньяк ур., 1нче йорт.

3. Гавами тыңлауларга чыгарыла торган мәсьәлә буенча тәкъдимнәрне һәм искәрмәләрне түбәндәге адрес буенча язма рәвештә 2025 елның 11 февраленә кадәр җибәрергә: ТР Лаеш районы Кече Кабан авылы, Южная ур., 1 йорт.

4. Әлеге карарны «Кама ягы» район газетасында бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә) һәм Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында http://laishevo.tatarstan.ru веб адресы буенча һәм Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Олы Кабан авыл җирлегенең махсус мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам

**Олы Кабан авыл җирлеге башлыгы** **И.Г. Шәрәфиев**